**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 01 » 07 2021 № 209

Аксубаево

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районында СПИД-ВИЧны профилактикалау һәм аңа каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия төзү турында

Район халкының иммунодефицит вирусы (ВИЧ-инфекция) белән авыруын киметү, риск төркемнәрендә һәм халык белән профилактик эшне көчәйтү, үткәрелә торган чаралар комплексының нәтиҗәлелеген арттыру максатларында һәм «Россия Федерациясендә Кеше иммунодефициты вирусы (ВИЧ-инфекция) китереп чыгаручы авыруларның таралуын кисәтү турында»1995 елның 30 мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль законны, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы СПИДка каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия турындагы нигезләмәне һәм аның составын раслау хакында» 2001 елның 11 сентябрендәге 635 номерлы Карарын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районында СПИД-ВИЧны профилактикалау һәм аңа каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия төзергә.

2. Расларга:

- Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районында СПИД-ВИЧны профилактикалау һәм аңа каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия составы (1 нче кушымта);
- Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районында СПИД-ВИЧ профилактикасы һәм аңа каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмә (2 нче кушымта).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aksubayevo.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Александровка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе: С.Ю.Зайцев

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль
районы Башкарма комитеты
.«__01__»__07__2021 № _209_
карары белән расланган
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы**
**Аксубай муниципаль районында СПИД-ВИЧны**
**профилактикалау һәм аңа каршы көрәш буенча**
**ведомствоара комиссия составы**

| | |
|---|---|
| 1. Зайцев С.Ю. | - комиссия рәисе, Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе |
| 2. Александров С.В. | - комиссия рәисе урынбасары, Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары |
| 3. Маланчева А.Н. | - комиссия секретаре, «Аксубай РҮХ»ДАССОның баш табибы урынбасары (килешү буенча) |
| Комиссия әгъзалары: | |
| 4. Сетрова О.П. | - Аксубай муниципаль районының финанс бюджет палатасы рәисе |
| 5. Ислямов М.И. | - «Аксубай РҮХ» ДАССОның баш табибы (килешү буенча) |
| 6. Зәйдуллина Р.С. | - Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф бүлеге» МКУ башлыгы |
| 7. Ибрагимов И.И. | - Татарстан Республикасы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгының Аксубай районындагы бүлеге ОУУП һәм ПДН башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| 8. Тимирясов А.С. | - Роспотребнадзорның ТР буенча идарәсенең Нурлат һәм Аксубай районнарында территориаль бүлеге башлыгы (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| 9. Зайцева Е.С. | - ТР Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Аксубай МР социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| 10.Канафин Р.К. | - Аксубай МР Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт буенча начальнигы |

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль
районы Башкарма комитеты
«01» 07 2021 № 209
карары белән расланган
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районында
СПИД-ВИЧка каршы көрәш буенча
ведомствоара комиссия турында нигезләмә

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының СПИД-ВИЧка каршы көрәш буенча ведомствоара комиссиясе (алга таба-Комиссия) Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы халкы арасында кеше иммунодефициты вирусы (СПИД, ВИЧ) профилактикасына һәм аңа каршы көрәшкә юнәлдерелгән бурычларны хәл итүдә кызыксынган учреждениеләрнең һәм оешмаларның килешеп эшләүләрен тәэмин итүче координацион орган булып тора.

2. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларына һәм күрсәтмәләренә, Россия Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм башка федераль башкарма хакимият органнарының карарларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы карарларына, Татарстан Республикасы Президенты указларына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә һәм башка норматив актларга таяна.

3. Комиссиянең төп бурычлары булып тора:

- Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы территориясендә кеше иммунодефициты вирусы (ВИЧ/СПИД) профилактикасы һәм аңа каршы көрәш өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыруны тәэмин итү буенча чаралар эшләү;

- кеше иммунодефициты вирусы (ВИЧ/СПИД) профилактикасы һәм аңа каршы көрәш өлкәсендә кызыксынучы учреждениеләр, предприятиеләр һәм оешмалар, шулай ук вазыйфаи затлар һәм гражданнар эшчәнлеген координацияләү;

- Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы территориясендә СПИДны профилактикалау һәм аңа каршы көрәш буенча норматив актларны камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү һәм билгеләнгән тәртиптә кертү.

4. Комиссия үзенә йөкләнгән бурычлар нигезендә түбәндәге функцияләрне башкара:

- кеше иммунодефициты вирусы (ВИЧ/СПИД) белән бәйле эпидемиологик процессның үсешен бәяли;

- Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы территориясендә озак вакытка исәпләнгән комплекслы чараларны эшли һәм контрольдә тота;

- ведомствоара чараларны тормышка ашыру процессын эшли һәм өйрәнә, килеп туган проблемаларны хәл итү буенча үз киңәшләрен бирә.

5. Комиссия хокуклы:

- Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы оешмаларыннан һәм учреждениеләреннән кеше иммунодефициты вирусы (ВИЧ/СПИД) белән авыруы турында, ВИЧ/СПИДны профилактикалау һәм аңа каршы көрәш өлешендә дәүләт сәясәтен үтәүнең барышы турында кирәкле мәгълүматны алырга;

- ВИЧ/СПИДны профилактикалау һәм аңа каршы көрәш, шул исәптән элегрәк кабул ителгән комиссия карарларын үтәү буенча чараларны гамәлгә ашыру турында Оешмалар һәм учреждениеләр җитәкчеләре, башка вазыйфаи затлар үз утырышларында тикшерүләр оештырырга, тыңларга.

6. Комиссиянең персональ составы һәм аның Рәисе Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан раслана. Комиссия әгъзалары комиссия эшендә шәхсән катнашалар.

7. Комиссия утырышлары кирәк булган саен, әмма кварталга кимендә бер тапкыр үткәрелә.

8. Комиссия карары күпчелек тавыш белән кабул ителә һәм билгеләнгән форма буенча беркетмә белән рәсмиләштерелә. Тавышлар тигез булганда, Рәиснең тавышы хәлиткеч булып тора.

9. Комиссия эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итү Татарстан Республикасының «Аксубай үзәк район хастаханәсе» ДАССО килешүе буенча гамәлгә ашырыла.